ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссуш.т.б.,423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru,www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» 09 2026 ел № 980

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 23.03.2026 ел, № 299 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында барлык дәрәҗәдәге бюджетларга түләүләр керүне тәэмин итү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт социаль ярдәме турында»гы 17.07.1999 ел, № 178-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Гражданнарга социаль ярдәм" Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында"гы 2014 елның 15 апрелендәге 296 санлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында, шул исәптән социаль контракт нигезендә» 25.12.2023 ел, № 1682 карары нигезендә,, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының "МНПАда ачыкланган коррупциоген факторлар турында" 17.07.2026 № 09/13-09/3964 хатына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 23.03.2026 № 299 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында барлык дәрәҗәдәге бюджетларга түләүләр керүне тәэмин итү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.7. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7. Комиссия утырышы йомгаклары буенча өч эш көне эчендә комиссия утырышы беркетмәсе рәсмиләштерелә, аңа комиссия рәисе һәм секретаре имза сала.

Комиссия утырышын уздырган көннән алып ун эш көне эчендә секретарь материаллар тарату юлы белән комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга карарларны җиткерә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М. Якупов
Тел. 8 (85593) 2-42-05